| Республика Татарстан<br>Исполнительный комитет<br>Верхне-Чершилинского сельского поселения Сармановского муниципального района | | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районының<br>Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитеты |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.03.2021ел №4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 02.05.2006 елдагы 59-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау (№1 кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга:

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы

Югары Чыршылы авыл җирлеге

Башкарма комитеты җитәкчесе И.Н. Камалетдинов

Югары Чыршылы авыл җирлеге

Башкарма комитет карарына

25.03.2021 № 4

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе.

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 12.05.2003 ел, № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсен үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә Анализ ясау гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшнең сыйфатын күтәрү, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында үткәрелә.

3. Тиешле чорда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә Анализ гражданнарның барлык мөрәҗәгатьләре, шул исәптән язма рәвештә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү аша җибәрелгән электрон документ рәвешендә, шулай ук вәкаләтле затлар тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча башкарыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләргә Анализ ел саен башкарыла.

5. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитеты сәркәтибе гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү нәтиҗәләре буенча хисап чорыннан соң килгән айның 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә кергән, яңадан каралган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләрнең саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхси кабул

итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый һәм башка актлар (булганда) турында мәгълүмат булырга тиеш.

7. Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә тиешле вакыт эчендә Анализ узган елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе ел саен аналитик белешмәнең Сарман муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүмат-телекоммуникация бүлегендә урнаштырылуын тәэмин итә

Интернет челтәре «авыл җирлекләре» бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр.